| | |
|---|---|
| ГЛАВА СОВЕТА<br>ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 октябрь, 2019 ел Хуҗа Хәсән авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең
Александровка торак пунктында гражданнар
җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 23 октябренә 15 сәг 00 минутка Александровка поселогының, Урман ур., 1 нче торак йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегең Александровка торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенынын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Александровка поселогы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева